Республика Татарстан

Глава Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы башлыгы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.04.2026 Менделеевск ш. № 23

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районында
Риза Газизов исемендәге еллык премия
бирү турында нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Уставы нигезендә һәм Менделеевск муниципаль районында яшәүче халыкларның мәдәни мирасын популярлаштыру һәм саклау, тел күптөрлелеген үстерү һәм милләтара татулыкны ныгыту, талантлы мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләренә ярдәм итү, аларның татар телен һәм район халыкларының туган телләрен саклау һәм үстерү өлкәсендәге иҗади эшчәнлеген стимуллаштыру, үз тормышын туган якка һәм аның кешеләренә хезмәт итүгә багышлаган күренекле эшлеклесе Риза Газизов истәлегенә тирән ихтирам билгесе буларак,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында Риза Газизовның еллык премиясен бирү турындагы нигезләмәне (1 нче кушымта).

1.2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында Риза Газизов исемендәге еллык премияне бирү комиссиясе составын (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: www.mendeleevsk.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының социаль мәсьәләләр буенча җитәкчесе урынбасары Ю.М. Рыбаковага йөкләргә.

Район Башлыгы Р.Р. Искәндәров

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башлыгының 2026 елның 10
апрелендәге 23  нче номерлы
карарына 1 кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында Риза Газизов исемендәге еллык премия бирү турында нигезләмә

1. Риза Газизов исемендәге еллык премия (алга таба - Премия) Менделеевск муниципаль районында яшәүче халыкларның татар телен һәм туган телләрен саклауга, үстерүгә һәм популярлаштыруга, шулай ук милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга һәм милли-мәдәни традицияләрне арттыруга зур шәхси өлеш керткәне өчен бирелә.
2. Премиягә лаек булган затларга «Риза Газизов исемендәге премия лауреаты» исеме бирелә, акчалата бүләкләү һәм диплом тапшырыла.
3. Премия аерым шәхесләргә бирелә (Лауреатларга премия кабат бирелми).
4. Премия күләме, физик затлар керемнәренә салымны исәпкә алып, 100 мең сум тәшкил итә.
5. Кандидатларны күрсәтү ел саен 13 апрельдән башлана һәм 22 апрельгә кадәр дәвам итә.
6. Устанавливаются следующие кандидатов на получение Премии:

**1. Тел үсешенә керткән өлешнең әһәмияте:**

- Татар телен һәм район халыкларының туган телләрен саклау, өйрәнү һәм популярлаштыру буенча эш күләме һәм сыйфаты.
- Конкрет нәтиҗәләр (нәшер ителгән китаплар, уку әсбаплары, медиапроектлар, методик эшләнмәләр һәм башкалар) булу.

**2. Иҗтимагый һәм мәдәни активлык:**

- Милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга юнәлдерелгән чараларны оештыруда катнашу.
- Районда милли-мәдәни традицияләрне үстерү өчен шартлар тудыруда инициатива булу.

**3. Иҗади нәтиҗәлелек:**

- югары сәнгати яки һөнәри эш дәрәҗәсе (мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре өчен).
- Казанышларны муниципаль, төбәк яисә федераль дәрәҗәдә тану (грамоталар, Рәхмәт хатлары, бүләкләр).

**4. Шәхси үрнәк һәм җәмгыятькә хезмәт итү:**

- Яшьләрне ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләүгә һәм мәдәни мирасны хөрмәт итүгә шәхси өлеш кертү.
- Актив гражданлык позициясе һәм кандидатның яхшы репутациясе.

**5. Эшнең озак вакытлы һәм системалы булуы:**

- Сайланган өлкәдә эшнең дәвамлылыгы һәм даимилеге.

Һәр критерий 10 баллы шкала буенча бәяләнә, җиңүче балларның суммар саны нигезендә билгеләнә. Баллар тигез булганда, уңышлы эшчәнлек тарихы озынрак булган кандидатка өстенлек бирелә.

7. Премиягә кандидатлар күрсәтелгәндә комиссиягә түбәндәге документлар белән тапшырыла:

- кандидатны күрсәтү турындагы үтенечнамә;
- эш тасвирламасы;
- кандидатның авторлык эшенең иң әһәмиятле элементлары турында күзаллау бирә торган өстәмә материаллар.

8. Тиешле документлар белән конкурс материаллары премияне бирү комиссиясе тарафыннан премиягә дәгъва кылуга кандидатларның документларын кабул итү тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә карала. Тәкъдим ителгән материалларны карау йомгаклары буенча комиссия премия лауреатларын билгели, утырыш беркетмәсен әзерли.

9. Комиссия утырышы беркетмәсе комиссия утырышы вакытыннан алып 3 эш көне эчендә имзалана һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башлыгына җибәрелә. Премия Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башлыгы карары белән комиссия утырышы беркетмәсе алынганнан соң 3 эш көне эчендә бирелә.

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башлыгының 2026 елның 10
апрелендәге 23  нче номерлы
карарына 2 кушымта

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында
Риза Газизов исемендәге еллык премияне бирү комиссиясе составы

| Ф.И.А.ис. | вазифа |
|---|---|
| Искәндәров<br>Роберт Ринат улы | комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башлыгы |
| Галеева<br>Ләйсән Камил кызы | Менделеевск муниципаль районы Башлыгы урынбасары, Менделеевск муниципаль районы Советы Рәисе урынбасары |
| Гыйльфанова<br>Эльмира Рәсим кызы | «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ милли мәгариф буенча методисты, комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары | |
| Бакаева<br>Надежда Александровна | Татарстан Республикасы рус милли-мәдәни берләшмәсенең Менделеевск бүлеге рәисе (килешү буенча) |
| Искәндәрова<br>Джулия Анатольевна | «Татмедиа» АҖ филиалы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Кәшипов<br>Илшат Гәбделфәт улы | «Менделеевск үзәне» балалар яшүсмерләр компетенциясе үзәге директоры |
| Кузнецова<br>Марианна Викторовна | Менделеевск районы удмуртларының җирле иҗтимагый оешмасы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Мамакова<br>Валентина Викторовна | Менделеевск районы керәшеннәре милли-мәдәни автономиясенең җирле иҗтимагый оешмасы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Миннәхмәтов<br>Идегәй Рафис улы | «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе» МКУ башлыгы |
| Нәҗипов<br>Рәис Габсәләм улы | «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы вазыйфаларын башкаручы |
| Рыбакова<br>Юлия Михайловна | Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының социаль мәсьәләләр буенча җитәкчесе урынбасары |
| Савельева<br>Эльвира Аркадьевна | Менделеевск районы марилары милли-мәдәни автономиясенең җирле иҗтимагый оешмасы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Фәрхетдинова<br>Рәйхана Ситдыйк кызы | «Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУК директоры, Бөтендөнья татар конгрессының җирле |

| | |
|---|---|
| | бүлеге җитәкчесе |
| Хәертдинова<br>Зөлфирә Хафиз кызы | «Бердәм Россия» партиясенең җирле бүлекчәсе башкарма секретаре (килешү буенча) |
| Хикмәтуллина<br>Регина Анатольевна | «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе» МКУ башлыгы |